

Мордовиядә, ботен донья белән бергә, изге Ураза гаетен бәйрәм иттек.

Ураза бәйрәменен асылы изге Рамазан аенда ураза тотып сынау узу, иманны ныгыту һәм рухи яктан чистарыну момкинлеге очен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт белдерv аша ачыла. Әлеге бәйрәмне vткәрvнен кvп гасырлык традицияләренә һәммәбез очен хәзер бик кирәкле зирәклек һәм тирән мәгънә салынган.

Милләтләр һәм диннәр арасында татулыкнын чын кыйммәте тиешенчә бәяләнгән, аны саклауга омтылыш кочле булган Мордовиядә Ураза гаете, барлык моселман, православие дини бәйрәмнәре һәм башка бәйрәмнәр кебек vк, vзара ихтирам, анлашу һәм дуслык рухында узды. Россия халыклары бердәмлеге елында боларнын әһәмияте тагын да арта.

Әйтеп китәргә кирәк, Мордовиянен һәрбер мәчетендә зурлап Уразаны vткәрделәр. Рузаевка районы Татар Пешләсе авылындагы «Җәмигъ» мәчете имам-хатыбы Абдуррахман хәзрәт Якупов аралашканда болай дип сойләде: «Мәчеттә авылдашларым ярдәме белән һәр атна vткәргән ифтарлардан сон, 20 мартта Ураза бәйрәменә жыелган менләгән якташ моселманнарыма догалар укыдым, хәер-фатихалардан сон, уразанын топ мәгънәсе турында сойләдем, vгет-нәсыйхәт, Ватанны ярату, гаиләдә диннен тоткан урыны турында халыкка житкерергә тырыштым. Спонсорлар ярдәме белән СВОда катнашучыларнын гаиләләренә ярдәм итеп киләбез.

Форсаттан кулланып, шәхсән vзем Рузаевка районы һәм Мордовия моселманнарын ихластан Ураза бәйрәме белән котлыйм! Илләребезгә Ходаем тынычлык бирсә иде, халкыбызга бәрәкәт, иминлек, татулык телим: саф кvнел белән яшик!»

Быел Ураза бәйрәмен мәчетләрдә генә тvгел, алдан әзерләнеп куелган зират алды мәйданчыкларында да укыдылар.

Темников, Атюрьево һәм Краснослободск районнары имам-мохтәсибе Рафик Фәрит улы Сайфетдинов Темников шәһәрендә һәм Зур Татар Карай авылында урнашкан мәчетләрдә Ураза бәйрәмен алып барды. Йола белән каралган догалардан сон нәселне саклау, тарихны белv, СВОда катнашучылар һәм башка темалар яктыртты. Кыскасы, иманнын кыйммәте эшләрдә икәнен ачыкладылар. Шулай, матур итеп Ураза бәйрәме vтте.

**Наилә НАСЫРОВА**